Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Глава Брюшлинского сельского поселения

Татарстан Республикасы
Менделевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
24.03.2025

КАРАР
№ 1

2024 елның 1 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2024 елның 1 ноябрендәге 2 номерлы " 2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 4 апрелендә 17.00 сәг. 2024 елның 1 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2024 елның 1 ноябрендәге 2 номерлы " 2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы, Бөрешле авылы, Заречная ур. 14 й. адресы буенча урнашкан Бөрешле авыл мәдәният йортында гражданнар җыенын уздырырга.

2. 2024 елның 1 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2024 елның 1 ноябрендәге 2 номерлы " 2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә сез ризамы” дигән сорауны гражданнар җыенында расларга һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш түшәлгән юлларда чокырларны ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Бөрешле авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бөрешле авылы территориясен чабу)?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштырып игълан итәргә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карар игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А.Смирнова